**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» март, 2026 ел № 181-п

Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 12.01.2026 елның 12 гыйнварындагы 3-п номерлы карары белән расланган «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «2026-2028елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2026елга финанслау» бүлегенә үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта таблицасын өстәргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 9 гыйнварындагы 2-р номерлы, 2026 елның 13 гыйнварындагы 11-р номерлы, 2026 елның 14 фералендәге 271-р номерлы боерыклары нигезендә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А. Харитоновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов

Кушымта №1
ТР Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_______________2026 ел

2026 елга финанслау

| Түләүләрнең атамасы | Сроклар | Сумма (мең сум) | Нормативный документ |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | 2026 | 554,01 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 14 февралендәге 271-р номерлы боерыгы |
| Спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру һәм күрсәтелгән оешмаларның спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм (яисә) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркемчәсе) катнашуы һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләрен үтәү | 2026 | 1250,1 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 14 февралендәге 271-р номерлы боерыгы |
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче ярышларда алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү | 2026 | 700,0 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 9 гыйнварындагы 2-р номерлы боерыгы |
| Хезмәткәрләргә-спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү | 2026 | 80 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 елның 9 гыйнварындагы 2-р номерлы боерыгы |